**Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 325-43 «10» март 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 14 апрелендәге 136-16 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны, гражданнарны шәхсән кабул итүне һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясауны тәэмин итү Нигезләмәсе турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны, гражданнарны шәхсән кабул итүне һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясауны тәэмин итү хакындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 10 августындагы 676 номерлы “Халык контроле" дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында гражданнарның, республика башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының электрон хезмәттәшлеге турында” гы карары нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы карар кабул итте

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 14 апрелендәге 136-16 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны, гражданнарны шәхсән кабул итүне һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясауны тәэмин итү Нигезләмәсе турында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауны, гражданнарны шәхсән кабул итүне һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясауны тәэмин итү хакындагы Нигезләмәгә (26.07.2022 №159-18, 14.12.2022 №196-20, 18.04.2023 №220-24 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.1 пункт. яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгать мәҗбүри каралырга тиеш, карау срогы – теркәлгән көннән алып утыз көн эчендә.

Хәбәрнамәне «Халык контроле» системасында карауның гомуми срогы 10 календарь көннән, «Коммуналь хезмәтләр», «Йортны агымдагы ремонтлау», «Йортны карап тоту» категорияләре өчен - өч календарь көннән артмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин